**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«19» июнь 2026 ел　　　　Иске Абдул авылы　　　　№ 05

**«Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм файдалану тәртибен раслау турында» 2023 елның 16 февралендәге 2 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясы 5 өлеше, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм файдалану тәртибен раслау турында» Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 16 февралендәге 2 номерлы карарына (Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетының 20.03.2025 № 3 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.7, 3.8 пунктларында «юл сервисы объектларын» сүзләреннән соң «элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын» сүзләрен өстәргә;

1.2. 2 статьяның 2.4 пункты 1 пунктчасында «элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын» сүзләрен өстәргә;

1.3. 2 статьяның 4 пункты 2 пунктчасында «элемтә линияләренә һәм элемтә корылмаларына» сүзләрен өстәргә;

1.4. 4 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4. «Автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары һәм (яки) юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен, элемтә линияләрен һәм элемтә корылмаларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, шул исәптән салу, күчерү һәм үзгәртеп кору, алардан файдалану».

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www. pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе　　　　Р.Х. Сафина